# ХӘЗЕРГЕ ХИКӘЯЛӘРДӘ ШАРТЛЫ-МЕТАФОРИК СУРӘТЛӘҮ ПОЭТИКАСЫ

**Насибуллова Г.Р.**
*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре*

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында җәмгыятьтә әхлакый һәм эстетик кыйммәтләр үзгәрү мәдәният белән сәнгатьне дә көчле чигенә китерә. Әдәбиятны яңартырга, шартлы сурәт мөмкинлекләреннән файдаланырга омтылыш та үзен нык сиздерә. Әдәбиятта традицион реализм кануннарыннан читләшкән һәм язучы аңында уйлап чыгарылган сәнгати чынбарлыкны (художественная реальность) чагылдыручы әсәрләр пәйда була. Әлеге чынбарлык реаль тормыш кануннарына буйсынмый, ә иҗади уйдырма психологиясе кануннары буенча яши. Автор өчен үзенең индивидуаль дөньясын, тирә-юньгә үз мөнәсәбәтен белдерү, чын тормышны күрсәтүгә караганда мөһимрәк була башлый. Язучылар күтәргән мәсьәләләр күбрәк фәлсәфи юнәлештә. “Шартлы-метофорик проза реаль тормышта абсурд, алогизм күрә, аның көндәлек агымында фаҗигале парадоксларны сизә. Ул шартлы формалар һәм алымнар артына яшеренгән реаль тормышның эчтәлеген ачыграк күрсәтү өчен фантастик элементлар куллана, геройларны гадәти булмаган мөмкинлекләр белән сыный. Шартлылык реаль нигезгә каршы килми, ә авторның тормыш концепциясен концентрацияләү чарасы булып хезмәт итә”. Югарыда билгеләнгән үзенчәлекләр Марат Кәбиров хикәяләрендә чагылыш таба.

Объектив дөньяны сурәтләгәндә, М. Кәбиров реалистик булмаган поэтикага һәм сәнгати экспрессия чараларына мөрәҗәгать итә. Аның әсәрләренең теленә төш поэтикасы, мистификация, гротеск хас. Мондый әдәбият хәзерге укучыны аеруча кызыксындыра, аның өчен әдәби текст үз заманының җитди фәлсәфи, тарихи мәсьәләләрен тулырак аңларга, универсаль рухи кыйммәтләрне ачарга мөмкинлек тудыра.

М. Кәбиров сәнгати дөньясы (художественный мир) берьяклы гына түгел, ул капма-каршылыкка корылган, бер үк вакытта абсурдлык хас һәм һәрвакыт чиктән тыш динамик. Язучы көндәлек көнкүреш җирлегендә миф, фантастика һәм реаль, иҗтимагый-тарихи чынбарлыкны янәшә чагылдыручы динамик сәнгати система төзи; биредә төсләр, әйберләр, күренешләр, предметлар даими рәвештә кискен үзгәреп тора.

Хәзерге әдәбиятта әлеге төр әсәрләрне иҗат итүнең этәргече булып, язучыларның бүгенге көндә мәңгелек сорауларның җимерелүен (преломление) күрсәтү теләге тора. Шартлы-метафорик сурәтләүгә корылган әсәрләрдә хәзерге заман кешесендә кешелеклелек һәм кешелеклелеккә каршылыкны символик чагылышы бирелә. Символ, аллегория, метафора форма ясауда катнаша, хакыйкатьне эзләү реализмга мөрәҗәгать итеп түгел, ә дини-мифологик алымнар ярдәмендә, кешенең аң агышы, геройларның әхлакый-психологик дөньясы аша башкарыла.

Язучы төсләр һәм мифопоэтика сурәтләре ярдәмендә чынбарлыкның әхлакый-фәлсәфи һәм иҗтимагый мәсьәләләрен күтәреп чыга: хакыйкатьне эзләү мотивы, җәмгыятьнең рухи деградациясе хакында кисәтү, халык аңының үзгәреш кичерүе һәм югары әхлаклылыкка таба юлда кирәкаккысыз каршылыклар очрау, әйләнә-тирәнең картинасын сатирик, гротеск планда сурәтли. Барлык бу әсәрләр шәхесне камилләшүгә генә түгел, ә явыз көчләргә каршы көрәшкә этәрә.

М. Кәбировның “Канатлы кеше” (2004), “Әҗәл җыры”, “Дүртенче үлчәм” (2004) кебек хикәяләрендә вакыйгалар реалистик, тормышчан кимәлдә тасвирлана да шартлы-уен чаралары белән алмашына. Болар тулысы белән шартлы, татар әдәбияты өчен модерннан соң (постмодернистик) кулланыла башлаган алымнарга бай әсәрләр.

“Дүртенче үлчәм” хикәясен гасырлар чиге татар әдәбиятында күзәтелгән яңарышның бер дәлиле дип атарга мөмкин. Хикәя – мәхәббәт хакында. Бергә гомер итеп, балалар үстереп тә, бер-берсенә самими, илаһи сөю хисен саклаган ир белән хатын тормышындагы бер кич хакында сөйләү сокландыра, мәхәббәтнең олылыгына мәдхия булып яңгырый.

Хикәядә вакыйгалар үстерелеше түгел, хис-кичерешләр көчеше үзәккә куелган. Ир белән хатынның мәхәббәт аңлашуы кебек үсә ул, ике кешедәге хисләрнең дә саф һәм тирән булуын исбатлый. Ләкин бу шарт әсәрне нәсер жанрына кертеп карауга җирлек бирми. “Дүртенче үлчәм”дә эпик төр таләпләренә җавап бирә торган тормыш моделе бар. Ул бик үзенчәлекле тәкъдим ителә.

Хикәядә реаль чынбарлык белән фантастика бергә үрелеп бирелә. М. Кәбиров хикәяләрендә күнегелгән тормыш тәртипләрен, рәвешен җимереп (деконструкция), тәртипсезлек (хаос) хасил итә яки яңа тәртип, рәвеш формалаштыра. “Дүртенче үлчәм” хикәясендә дә без күнеккән аксиомалар юкка чыгарыла. Ир, үз хатынына сөю хисенең зурлыгын исбатлап, айны болыт

артыннан чыгара, аннары йолдызларны бер-бер артлы кабызып җибәрә, аларны биетә, таң аттыра һәм үзләрен яшьлеккә кайтара. Язучы әлеге могҗизаның мөмкин икәнлегенә укучыны ышандыра, деконструкция алымын куллана. М. Кәбиров шартлы-метафорик сурәтләү аша фәлсәфи фикер җиткерә: мәхәббәт – шулкадәр зур көч, ул хәтта могҗизага да сәләтле.

Хикәя лирик-эмоциональ дулкында язылган, ир белән хатынның сөйләшүе шулкадәр җылы һәм самими, нәкъ менә шул сөйләшү кеше күңеленең бай һәм тирән булуын күрсәтә. Сөйләшү һәм хис үсеше хикәяләүче тарафыннан бәян ителә. Айны, йолдызларны кабызу, яшьлеккә кире кайтырга омтылу татар халык җырлары белән ассоциациягә керә.

“Канатлы кеше” хикәясе дә шушы кимәлдә иҗат ителгән. Хикәядә бер подъезда яшәүче биш дус хакында сөйләнелә: милиция майоры Нәҗип, хирург Шакир, шахматчы Азамат, атлет Хөрмәт һәм очучы Нури. Шакир дусларына авыр операция ясаганлыгын, автомобиль һәлакәтенә эләккән Таһир язмышын сөйли. Таһирны бу тормышка үз алдына максат кую кире кайтара. Монда аңа табиб Шакир ярдәм итә. Операциядән соң Таһир кәгазьгә “Мин яшәргә телим” дип яза. Бераздан аның яшәячәге билгеле була. “Мин сөйләшергә телим”, “Мин йөрергә телим” теләкләре дә чынга аша. Бу хәл тарафыннан могҗиза буларак кабул ителә. Моны хикәяләүче үзе дә раслый. (“Тик аның аякка басуы ышандырмый – бу медицина кануннарына каршы килә торган гаҗәп бер хәл булыр иде”, “Бу сүзләрне бөтен кануннарга каршы килүен белсә дә, хәзер ул Таһирга ышана, аның канатларын җилпеп шушы йортлар өстеннән үтә алуына тамчы да шикләнми иде” [1]). Әлеге хикәя кешенең мөмкинлекләре чиксез булуы турында. Ул, “максат куйганда, кеше һәрвакыт мөмкин булмаганга да ирешә” дигән идея белдерә. Әлеге фикер хикәянең соңгы юлларында иң биек ноктага җиткерелә: “Һәркайсы үз өлкәсендә ниндидер дәрәҗәгә ирешкән, яшәү шартларын җайга салган, һәрберсенең күкрәк сугып “Мин!” диярлек мөмкинлеге булган гамәли карашлы асыл ирләр, бергә җыелгач, үзләре дә сизмәстән, вакыт-вакыт һавага карап алалар да күзләрендә чиксез сагыш, сүрелмәс өмет балкып китә иде” [1]).

Хикәяләрдә яктылык, кешенең бөеклеге, кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрнең матурлыгы хакында сөйләнелә. Әсәрләрдә язучы мәхәббәтнең, дуслыкның нинди могҗиза, никадәр матур, илаһи хис икәнлеген арттыру ярдәмендә сурәтләсә, “Әҗәл җыры” әсәрендә гротескны ямьсезлекне, вәхшилекне чиктән тыш арттырып күрсәтү өчен куллана. Хикәядә реаль тормыш артык натураль сурәтләнә. Әсәр нигезендә көндәлек тормыштагы вакыйгалар ята. Хатын бертөсле тормыштан туеп башта ирен агулап үтерергә ниятли, эше барып чыкмагач, пычак белән кадый. Бу бүгенге көндә еш очрый торган күренеш. Хикәянең икенче катламын – фантастик катламын – хатынның төше, саташулары тәшкил итә.

М. Кәбировның “Табут” хикәясендә сатира гротеск дәрәҗәсенә җитә. Әсәрнең үзәгендә реаль җирлектә конкрет бер вакыйга сурәтләнсә дә, шартлылык күзгә ташланып тора. Язучы дөньяны шартлы рәвештә икегә аера: байлар һәм ярлылар. “Берәүләре очын очка ялгап җан асрый, икенчеләре, балда-майда йөзеп, байлык туплый. Һәм боларның берсе дә тыныч күңел белән яши алмый иде. Беренчеләре ярлылыктан арыну турында уйланып башын катырса, икенчеләре караклардан, адәм талаучылардан дер калтырап гомер сөрә, шул куркуларын бераз киметү өчен, бозау хәтле этләр асрыйлар иде” [1].

“Шартлы-метафорик сурәтләүгә характерларның психологик тирәнлеге хас түгел. Индивид дәрәҗәсендә тормышка ашырыла торган психология шартлы-метафорик прозаның сурәтләү чараларына керми. Ул индивидуальлектән өстен (надындивидуальное) яки индивидуальлектән читтә (внеиндивидуальное) булган әйберне тасвирлый. Хәтта геройда үзенә генә хас булган үзенчәлек чагылыш тапса да, бу характер гына түгел, ә, беренче чиратта, фәлсәфи идеяның яки социаль билгенең тормышка ашырылуы”. Язучы һәрберсенең бер вәкиле хакында бәян итә, Әүхәт белән Нәгыйм икесе ике төркемгә карый, алар янәшә яши, очрашканда исәнләшеп узалар.

Хикәянең реалистик катламында Әүхәтнең эте Нәгыймнең малаен тешли. Эт – байлар катламы өчен беренчедән, матди хәлне күрсәтә, икенчедән, “эт ул – кодрәт, таяныч. Бер ым кагу белән дошманыңны ботарлап ташларга әзер торган хайван янында, кеше үзен КЕШЕ итеп тоя” [1; 2], көч-кодрәт символы. Этнең исеме дә символик мәгънәгә ия. Лимон гади сөйләмдә акча дигәнне аңлата, ягъни бер миллион. Нәгыйм эттән үч ала – аны үтерә. Автор улының кулын тешләгән эт белән Нәгыйм арасындагы каршылыкны гына сурәтләми. Чынлыкта әсәрдәге конфликт катлаулырак һәм тирәнрәк. Биредә эт әнә шул Әүхәтләр катламын, башкалар очын-очка ялгап яшәгәндә, кеше хисабына көн күрүчеләрне чагылдыра. Конфликт ике система арасында бара: байлар һәм гади халык. Соңыннан ир әлеге гамәле өчен үкенә һәм газаплана. Аны курку хисе били. Хикәядәге табут образы да символик мәгънәгә ия. Әүхәт ике табут ясата: беренчесе – эте өчен, икенчесе – үтерүчегә. Этнең “мескен генә бер бәндә… Гомере эчендә бер егетлек эшләргә дә

тәвәккәллеге җитмәгән бозау ир… Ни үзен, ни гаиләсен карый алмаган бер булдыксыз… тарафыннан үтерелүе, бу, чынлап та, Әүхәтнең башына сыймаслык хәл иде. Бу: Лимонны яңа туган бозау сөзеп үтергән, яисә песи талаган,” - дигән кебегрәк яңгырый иде. Ләкин Лимон үлгән һәм аны Нәгыйм ерткычларча үтергән” [1].

Язучы таланты тудырган дөнья котылгысыз булып өскә килә. Бу чынбарлык образы укучыга бер генә юл калдыра кебек – чиксез тетрәнү һәм шул нигездә тазарыну (катарсис), рухи уяну. Әмма язучы моның белән генә тукталып калмый. Әсәрнең идеясе “Күрегез, сез нинди шакшы дөньяда яшисез!” белән генә чикләнми.

Автор әсәрләрендә сәнгать алымы буларак аллюзияләрне еш куллана. Билгеле әсәргә читләтеп ишарә ясау нигезендә аның белән охшашлык яки аермалы яклар әсәрдә өстәмә мәгънәви ассоцацияләр тудыра, алар әсәрне баета. М. Кәбировның “Табут” хикәясе рус классигы А.П. Чеховның “Чиновник үлеме” әсәрен искә төшерә. Биредә дә Нәгыймне әлеге хикәядәге чиновникны сыман куркаклыгы, үзеннән өстен катлам вәкиле каршында тез чүгүе үлемгә китерә.

Хикәя классик һәм классик булмаган сәнгати системалар, реалистик һәм модернистик структуралар каршылыгы һәм синтезы арасында калса да һәрвакыт үсештә. М. Кәбиров әсәрләренең поэтикасында пародиячелек, гротеск-фантастик башлангыч, экспрессив детальләр куллану, сурәтлелекнең контрастлыклыгы татар әдәбиятында яңа иҗат алымы – шартлы-метафорик сурәтлелек килеп керүе хакында сөйли.

**Литература**

1. Кәбиров М. Табут: хикәя / Марат Кәбиров // Ватаным татарстан. – 2008. – 6 июнь.
2. Сверигин Р. Аны беләбезме? (Ф.Яруллинга 65 яшь тулу уңаеннан) / Р.Сверигин // Казан утлары. – 2003. – № 2. – Б. 130-137.